Раслыйм
Бакый Урманче исемендәге
"2 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми
белем бирү учреждениесе директоры
А.Н.Гаязова
"29" августа 2020 ел

# Бакый Урманче исемендәге "2 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең "Үсеш" балалар оешмасы эшчәнлеге программасы

Түбән Кама

2020 нче ел

## *АҢЛАТМАЛЫ ЯЗУ*

Россиядә һәм Татарстандагы хәзерге иҗтимагый һәм социаль-политик үзгәрешләр, балалар һәм яшүсмерләрнең тормышта шәхес булып җитлегүендә дә проблемалар тудырды.

Үзидәрәнең нигезе булган балалар оешмалары социаль үсеш һәм тәрбия өлкәсендә зур көч булып тора. Балалар оешмасы балалар һәм яшүсмерләр өчен мөстәкыйль фикерләү, мөстәкыйль карарлар кабул итү, идарә эшенә өйрәнү мәктәбе булып тора һәм аларга тормышта үз урыннарын табырга дөрес юнәлеш бирә.

Укучылар оешмасының яшүсмерләрне тәрбияләүдә мөмкинлекләре зур:

- күпкырлы җәмәгать эшчәнлеге аркылы төрле юнәлеш, эшчәнлектә сәләтләрне ачу һәм үстерү;
- шәхес булып җитлегү чорында балаларның үз мөмкинлекләрен җәмәгать эшчәнлегендә сынап карау һәм уңышка ирешү юлларын табу;
- җәмәгать эшен башкарганда балаларның мөстәкыйльлеген үстерү;
- балалар оешмасындагы эшләрне мөстәкыйль сайлау, башкару, коллектив эштә үз теләге белән катнашу, уртак максат куеп күмәк эшнең уңай нәтиҗәсен күрү ихтыяҗын канәгатьләндерү;
- оешмада бер-берсенең фикерен тыңлап, тату, бердәм хезмәттәшлек итә белү;

Балалар оешмасы мөстәкыйль тормышка әзерләнү, тәҗрибә туплау, шәхесләр арасында хөрмәт, түземлелек, янәшә тату яшәү, коллектив мәнфәгатен алга куеп фикер йөртү, тормыштагы яхшы һәм начар күренешләргә дөрес бәя биреп, уңай үрнәктә тәрбияләнү, патриотик рухта үсү җирлеге булып тора.

"Үсеш" балалар оешмасы программасы җәмәгать оешмалары турында закон (1995 ел), мәгариф законы, балалар хокукларын яклау турындагы конвенциягә, "Яшьләр турында" һәм "Мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү" дип аталган законнарга нигезләнеп төзелә.

Программа 1-11 сыйныф укучыларын күздә тотып 3 ел дәвамында тормышка ашырыла.

***Программаның максаты:***

Балалар һәм яшьләр хәрәкәтен үстерү, югары сыйныф укучыларында гражданлык һәм патриотизм хисәре формалаштыру, мөстәкыйль шәхес тәрбияләү.

***Программаның бурычлары:***

- оешмада бер-берсенең фикерен тыңлап, тату, бердәм хезмәттәшлек итә белү;

Балалар оешмасы мөстәкыйль тормышка әзерләнү, тәҗрибә туплау, шәхесләр арасында хөрмәт, түземлелек, янәшә тату яшәү, коллектив мәнфәгатен алга куеп фикер йөртү, тормыштагы яхшы һәм начар күренешләргә дөрес бәя биреп, уңай үрнәктә тәрбияләнү, патриотик рухта үсү җирлеге булып тора.

“Үсеш” балалар оешмасы программасы җәмәгать оешмалары турында закон (1995 ел), мәгариф законы, балалар хокукларын яклау турындагы конвенциягә, “Яшьләр турында” һәм “Мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү” дип аталган законнарга нигезләнеп төзелә.

Программа 1-11 сыйныф укучыларын күздә тотып 3 ел дәвамында тормышка ашырыла.

***Программаның максаты:***

Балалар һәм яшьләр хәрәкәтен үстерү, югары сыйныф укучыларында гражданлык һәм патриотизм хисәре формалаштыру, мөстәкыйль шәхес тәрбияләү.

***Программаның бурычлары:***

- коллектив эшчәнлегендә укучыларның иҗади күнекмәләрен үстерү;
- буш вакытны файдалы куллану;
- яшүсмернең социаль активлыгын үстерү;
- укучы яшьләрнең мәктәп оешмаларындагы функциональ эшчәнлеген координацияләү.

***Программаның төп юнәлешләре:***

1. Һәр шәхеснең иҗади эшчәнлеген һәм мәнфәгатьләрен, үзтәрбия һәм үзидарә эшен үстерү.
2. Коллективның иҗади эшчәнлеген, җәмгыятьтә кирәкле юнәлеш алган юлларын өйрәнү.
3. Җәмгыятьтә яшәү өчен кирәкле уңай күнекмәләрне үстерү.
4. Балалар оешмалары эшчәнлеген камилләштерү, балалар оешмасы әгъзаларының кызыксынуларын, мәнфәгатьләрен исәпкә алып, эш системасын яңарту.
5. Балалар оешмасының башка җәмгыять оешмалары белән элемтәсен урнаштыру.

6. Төрле оешмаларның бердәм таләпләрен һәм эшчәнлекләрен координацияләү.

***Программаның эчтәлеге:***

Гимназиянең “Үсеш” оешмасы үзидарәнең башкаручы органы булып тора. Ул И.Х.Садыйков исемендәге каршындагы шәһәр Балалар Иҗаты Үзәге укучылар советына буйсына; балалар оешмалары иҗтимагый хәрәкәтенең бер өлеше. Алар яшь буынны тормышка әзерләүдә, аның мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклауда зур әһәмияткә ия.

“Үсеш” оешмасының төп максаты – гимназия укучылары, педагогик коллектив, яәмәгатьчелек, ата-аналар белән хезмәттәшлек. Программа һәр баланың мөстәкыйль шәхес буларак һәръяклап ачылуын күз алдында тота. Балаларның эшчәнлеге һәр ел саен үзгәреп, яңарып тора. Яңалыкны укучылар оешма эшчәнлегенә үзләре кертә.

***Югары сыйныф укучылар советының эшчәнлек принциплары:***

***УСЕШ***

***Ү***зебез

**С**айлыйбыз

Эзлибез

***Ш***өгыльләнәбез

***Юнәлешләр:***

1. ***Уку, фән, белем*** – мөстәкыйль белем алу, алган билемнәрне куллана белү, фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү күнекмәләре үстерелә.
2. ***Ватан*** - әхлак – туган илгә, җиргә кешеләргә мәхәббәт, әдәп-әхлак мөнәсәбәтләре тәрбияләнә, кешеләр белән яхшы мөгәмәлә урнаштырырга игътибарлы, ихтирамлы булырга өйрәтә.
3. ***Спорт-сәламәтлек*** – сәламәт яшәү рәвешен тән, җан, рух, әйләнә-тирә сәламәтлеген ныгыту күнекмәләре бирә.
4. ***Мәдәният*** – милли һәм гомумкешелек, халык традицияләрен дәвам итүче, күпкырлы үсеш алган, әйләнә-тирәдә матурлык тудыручы, аны саклучылар тәрбияли, укучыларның сәләтен үстерә.
5. ***Хезмәт*** – үз-үзеңә һәм җәмгыятькә файдалы эшләр башкарырга өйрәтә.

## *I. Уку, фән, белем*

| № | Эшчәнлек | Сыйныфлар | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | - Белем бәйрәменә багышланган «Беренче кыңгырау», «Батырлык» дәресе;<br>- Түгәрәк, спорт секцияләре, студияләргә язылу. | 1-11<br>1-11 | Сентябрь |
| 2. | - Укытучылар көне, «Дублер” көне;<br>- Хат язу атналыгы;<br>- Түгәрәкләргә язылу; | 10-11<br>1-11<br>1-11 | Октябрь |
| 3. | - Гимназия күләмендә һәм шәһәр олимпиадаларында катнашу;<br>- Фән атналыклары;<br>- Фән түгәрәкләренә йөрү. | 1-11<br>1-11 | Ноябрь |
| 4. | - «Әлифба» белән саубуллашу» бәйрәме;<br>- Фән атналыклары; | 1<br>1-11 | Декабрь |
| 5. | - Шәһәр олимпиадалары; | 1-11 | Гыйнвар |
| 6. | - Лекторлар төркеме эше; | 9-11 | Февраль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Шәһәр олимпиадаларында катнашу | 1-11 | |
| 7. | - Дублер көне. | 10-11 | Март |
| 8. | - Имтиханнарга әзерлек, курслар;<br>- «Соңгы кыңгырау» бәйрәме | 9, 11<br>9, 10, 11 | Апрель |
| 9. | - Имтиханнарга әзерлек һәм тапшыру;<br>- Башлангыч сыйныфларда саубуллашу кичәләре; | 9, 11<br>1-4 | Май |

## *II. Ватан*

| № | Эшчәнлек | Сыйныфлар | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | - Батырлык дәресләрендә ветераннар белән очрашу;<br>- Шәһәр, гимназия музеена экскурсия;<br>- Ветераннар йортында яшәүче ялгыз өлкәннәргә ярдәм «Шәфкатьлелек» операциясе. | 1-11<br>1-11<br>5-10 | Сентябрь |
| 2. | - Өлкәннәр көне. «Янәшәдә ветеран яши» акциясе;<br>- Укучылар оешмасы: «Алар комсомолда тәрбияләнгән»;<br>- Гаилә шәҗәрәсе өйрәнү;<br>- Музейда «Иң яхшы шәҗәрә» конкурсы<br>- Укытучылар көне «Ветеран укытучы», «Безнең иң яхшы укытучыларыбыз»;<br>- Сыйныф сәгатьләре: «Өлкәннәрне кадерлик», «Олыларның сүзе алтын» һ.б. | 5-10<br>1-11<br>1-11<br>1-11<br>1-11<br>1-11 | Октябрь |
| 3. | - 4.11 – халыклар бердәмлеге көненә багышлап сыйныф сәгатьләре, лектор төркемнәре эшчәнлеге, газета чыгару;<br>- Музейда Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап экспозицияләр яңарту. | 1-11 | Ноябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 1-11 | |
| 4. | - Ялгыз инвалид өлкәннәргә тимурчылык ярдәме;<br>- Музейда Батырлык дәресләре «Булачак солдатларга киңәшем», «70 ел сызлый яралар» — Батырлык көне;<br>- Батырлар көненә багышланган сыйныф сәгатьләре;<br>- Афганчылар белән очрашу. | 5-10<br>1-11<br>1-11 | Декабрь |
| 5. | - «Кышкы десант» — өлкәннәргә ярдәм;<br>- «Бабам истәлекләре», «Әбием дәресләре» — каникулда гаилә шәҗәрәсен өйрәнү. | 5-10<br>1-11 | Гыйнвар |
| 6. | - Патриотик тәрбия айлыгы;<br>- Батырлык дәресе: «Баһадирлар безнең янәшәдә», «Батырлыкка һәрвакыт урын бар»;<br>- Очрашулар: «Сез һаман да безгә бик кирәк». | 1-11<br>1-11<br>1-11 | Февраль |
| 7. | - Шәһәр, гимназия, республика тарихи музейларына сәяхәт «Үткәннән бүгенге аша киләчәккә барабыз»;<br>- Гаилә шәҗәрәсен өйрәнүне дәвам итү «Әби-бабай сөйләгәннәрдә — гаиләбез тарихы»;<br>- Ветеран укытучыларны котлау, очрашу «Гимназия кичә, бүген, иртәгә». | 1-11<br>1-11<br>1-11 | Март |
| 8. | - Музейда очрашулар: «Сугыш эзләре буйлап»;<br>- «Гаиләм тарихында Ватан сугышы эзләре»;<br>- «Алар җиңү яулаучылар» — сугыш ветераннарының тормышын өйрәнү, альбом төзү; | 1-11<br>1-11<br>1-11 | Апрель |
| 9. | - «Хәтер» атналыгы<br>- «Картаймагыз әле, ветераннар!» — акция: ярдәм, бүләкләр, котлау, концерт, очрашулар; | 1-11<br>1-11 | Май |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - «Батырлык» дәресләре: «Дан сиңа, дан, солдат!»;<br>- Ветераннар йортында яшәүчеләргә тимурчылык ярдәме;<br>- Республиканың тарихи урыннарына сәяхәтләр. | 1-11<br>5-10<br>1-11 | |
| 10 | - Хәтер көне | 1-4 | Июнь |

## *III. Спорт-сәламәтлек*

| № | Эшчәнлек | Сыйныфлар | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | - Юл йөрү ункөнлеге;<br>- Эвакуация планы белән таныштыру;<br>- 4.09 – 4.10 — гражданнарны саклау айлыгы;<br>- ГИБДД, УВД, прокуратура, балалар поликлиникасы белгечләре белән очрашу; | 1-11<br>1-11<br>1-11<br>1-11 | Сентябрь |
| 2. | - Сәламәтлек көне;<br>- Көзге экскурсияләр; | 1-11<br>1-11 | Октябрь |
| 3. | - Көзге каникулларда табигатькә экскурсияләр. «Көзге ямь»;<br>- Хокук бозу һәм наркотик матдәләр куллануны кисәтү айлыгы. | 1-11<br>1-11 | Ноябрь |
| 4. | - Инвалидлар ункөнлеге: «Физик кимчелеге булган балалар белән эш». «Минем мавыгуларым» — кул эшләре күргәзмәсе, «Мин дә сезнең яшьтәшегез» — гаилә фотоальбомнары күргәзмәсе;<br>- «Кыш Бабай олимпиадасы» — кышкы спорт ярышлары; | 1-11<br>1-11 | Декабрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | - Кышкы каникулларда экскурсия, поход, табигатькә чыгу, спорт уеннары; | 1-11 | Гыйнвар |
| 6. | - Спорт уены «Зарничка»;<br>- Спорт ярышлары;<br>- Хәрби җырларны сәхнәләштерү конкурсы<br>- “Ягез әле, егетләр!” конкурсы<br>- “Строй җырлары” конкурсы | 1-4<br>1-11<br>1-4<br>10-11<br>10-11 | Февраль |
| 7. | - Экскурсия, походлар, табигатькә сәяхәт;<br>- Спорт бәйрәме, спорт ярышлары. | 1-11<br>1-11 | Март |
| 8. | - Язгы спорт ярышлары;<br>- 8.04 — Сәламәтлек көне;<br>- «Безопасное колесо» — шәһәр конкурсына әзерлек һәм катнашу. | 1-11<br>1-11<br>7 | Апрель |
| 9. | - Экскурсияләр, походлар;<br>- Спорт ярышлары;<br>- Сабантуй бәйрәмендә спорт уеннары;<br>- Туристик поход;<br>- В.Винников истәлегенә футбол ярышлары. | 1-11<br>1-11<br>1-11<br>9-11<br>8-10 | Май |

## *IV. Мәдәният*

| № | Эшчәнлек | Сыйныфлар | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | - Түгәрәкләргә язылу;<br>- «Беренче кыңгырау» линейкасы<br>- Уңыш бәйрәме, көзге композиция, фоторепортаж | 1-11<br>1-11 | Сентябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «Алтын көз»;<br>- Гимназистлыкка багышлау | 1-11<br>1 | |
| 2. | - «Өлкәннәр көне»нә багышланган шәфкатьлелек операциясе “Иң кадерле кешеләребез”<br>- Укытучылар көненә концерт «Сез иң гүзәл кеше икәнсез»;<br>- Стенгазета, фоторепортаж, сочиненияләр конкурсы «Гимназия — минем юл башым». | 5-10<br>1-11<br>1-11 | Октябрь |
| 3. | - «Уңыш бәйрәме»;<br>- «Әниләр көне»нә багышланган чаралар: «Иң кадерле әнием», «Әнием миңа үрнәк» — әниләр өчен бәйрәмнәр. | 10-11<br>1-11 | Ноябрь |
| 4. | - Кыш Бабай остаханәсе: кабинет бизәү, уенчыклар ясау, газета чыгару;<br>- Яңа ел кичәләре | 1-11<br>1-11 | Декабрь |
| 5. | - Каникул чорында мәдәни чараларда катнашу<br>- Гимназия укучылары белән очрашу кичәсенә әзерлек. | 1-11<br>11 | Гыйнвар |
| 6. | - Очрашу кичәсе «Гимназия безне кабат җыя»;<br>- Ветераннар өчен концерт: «Күңелләрдә дәртләр сүнмәсен».<br>- Патриотик җырларны сәхнәләштерү «Җырлыйбыз да, уйныйбыз да»...<br>- Сочинение, рәсем конкурслары; | 11<br>1-11<br>1-4<br>1-11 | Февраль |
| 7. | - Укытучыларны котлау, концерт «Сезнең алда баш иябез»; | 1-11 | Март |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Ветеран укытучыларны хөрмәтләү;<br>- Кино, театр, циркка культпоходлар;<br>- «Нәүрүз» бәйрәме;<br>- «Ягез әле, кызлар!» — конкурс. | 1-11<br>1-11<br>1-11<br>10-11 | |
| 8. | - Ветераннар өчен концерт әзерләү: «Фронтта һәм тылда җиңүчеләргә». | 1-11 | Апрель |
| 9. | - «Соңгы кыңгырау» — концерт номерлары;<br>- «Сабантуй» милли бәйрәме;<br>- Шәһәркүләм «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә катнашу; | 10-11<br>1-11<br>11 | Май |
| 10. | - Шәһәр “Сабантуй” бәйрәмендә катнашу | 3-11 | Июнь |
| 11. | - Шәһәр көнендә катнашу | 8-11 | Август |

## *V. Хезмәт*


| № | Эшчәнлек | Сыйныфлар | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | - Санитар чәршәмбеләр;<br>- «Буыннар бакчасы»нда эш. | 5-11<br>7-10 | Сентябрь |
| 2. | - Санитар чәршәмбеләр;<br>- «Буыннар бакчасы»нда эш.<br>- «Эзтабар» сафларына кабул итү. | 5-11<br>7-10<br>1 | Октябрь |
| 3. | - «Варислык» сафларына кабул итү.<br>- Укучыларның һәм аларның әниләренең кул эшләре күргәзмәсе «Әниемнән өйрәнәм»; | 5<br>1-11 | Ноябрь |
| 4. | - «Янәшәдә батырлар яши!» — акциясе; | 5-10 | Декабрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Яңа ел кичәләрен әзерләү, үткәрү | 1-11 | |
| 5. | - Гимназия территориясен кардан чистарту<br>- Ветераннарга тимурчылык ярдәме. | 7-11<br>5-10 | Гыйнвар |
| 6. | - Ветераннар йортына ярдәм «Тимурчылык десанты»;<br>- Очрашу кичәсенә әзерлек һәм үткәрү;<br>- Чыгарылыш сыйныф укучыларының гимназияне тәмамлаган элекке укучыларының уку йортлары һәм һөнәрләре белән танышу. | 5-10<br>11<br>11 | Февраль |
| 7. | - «Кошлар көне»: оялар ясау, стена газетасы «Кошлар — безнең дусларыбыз»;<br>- Санитар чәршәмбеләр. | 5<br>5-11 | Март |
| 8. | - Ветераннарга ярдәм, тимурчылык эше, бүләкләр әзерләү;<br>- Һөнәрләр ярминкәсендә катнашу;<br>- Уку йортларында ачык ишекләр көнендә катнашу;<br>- Санитар чәршәмбеләр;<br>- «Парклар маршында» катнашу.<br>- Һөнәри юнәлеш (тест, анкета, белгечләр белән очрашулар); | 5-10<br>9-11<br>9-11<br>5-11<br>7<br>9-11 | Апрель |
| 9. | - Санитар чәршәмбеләр<br>- «Буыннар бакчасында» эш<br>- Җәйге хезмәт чиреге;<br>- Тәҗрибә кишәрлегендә эш.<br>- Төрле белгечләр белән очрашулар. | 5-11<br>7-10<br>5-10<br>5-10<br>1-11 | Май |
| 10. | - Буыннар бакчасында, тәҗрибә кишәрлегендә эш | 5-10 | Июнь |

***Программаның катнашучылары:***

- Гимназиянең 1-11 сыйныф укучылары;
- Гимназиянең педагог-оештыручылары;
- Кызыксыну буенча оешмалар;
- Балалар оешмалары.

***"Үсеш" балалар оешмасы үзидарәсе моделе***




***Берлекләрнең функцияләре:***

1 .Президент оешма эшне планлаштыра, анализлый:

- берлекләрнең эшен җитәкли;
- утырышлар үткәрә.

2. Вице-президент:

- барлык эшчщнлектщ президентның төп ярдәмчесе һәм аны алыштыра;
- төркем берлегенң утырышларын үткәрә;
- күмәк эшләрдә катнашу активлыгын исәпкә ала;
- беркетмәләр язу һәм документлар өчен җавап бирә;

3.Җитәкче көндәлек эшләрне оештыра, программа үтәлешен тәэмин итә.

4.Иҗади берләшмә:

- күмәк чаралар оештыра;
- концерт, конкурс, викторина үткәрә;
- акцияләр оештыра;
- сәламәтлек чаралары оештыра.

5. Фәнни берләшмә җитәкчесе:

- укучыларның уку, фән белән шөгыльләнү эшләрен оештыра

6. Оештыручы педагог актив белән эш оештыра.